Әрекмән-тигәнәк

ТАБИГАТЬ ҺӘМ БЕЗ

Ул һәрвакыт кешеләр белән янәшә яши. Кояш төшмәгән лапас артларында, чүплекләрдә. Чокыр кырыйларында аның зур-зур яфраклары очратырга мөмкин. Ләкин шатландырырлык бер ягы бар: ул уңдырышлы туфракны ярата. Әгәр әрекмән үсә икән, ул җирдә, һич курыкмыйча, яшелчә түтәле ясарга мөмкин.

Кечкенәрәк вакытта без аны әрекмән дип атасак, җимешләре өлгергәч, тигәнәк дип атап йөртә башлыйбыз. Әрекмән яфраклары фил колакларын хәтерләтә. Әллә киресенчәме? Аларның диаметры 50 сантиметрга кадәр житә, сабакка чиратлашып урнашалар. Сабакның озынлыгы 60-150 сантиметр, караңгырак урыннарда ике метрга хәтле житә. Безнең якларда ул июнь-июль айларында чәчәк ата, чәчәкләре чия кызгылт төстә, чикләвекне хәтерләтә. Әрекмән ике еллык үсемлек. Беренче елда тамыр янындагы яфраклар гына күренә, ә икенче елда җимешләре өлгергәч, ул корый. Без чүп үлән дип һәрчак котылырга теләгән шушы әрекмәннең гажәеп файдалы үзлекләре бар. Коры печәнендә 18,4 процент протеин, 14,4 – аксым, 1,5 – май, 22,3 процент клетчатка бар. Әлбәттә, әрекмәнне хужалыкларда печән өчен үстермиләр. "Балтырганы беләктәй" диелгән "Идегәй" дастанындагы кебек, әрекмәннең беләк юанлыгы сабагын киптерү – үзе бер газап. Әмма ерактан күренеп торган чәчәкләреннән бал кортлары һәм төклетуралар нектар җыя. Беренче елындагы әрекмәннең яшь тамырларыннан ясалган салатны Франциядә, Бельгиядә, Америкада, Кытайда рәхәтләнеп ашыйлар. Японияда әрекмәнне хәтта түтәлләрдә үстерәләр. Сусыл һәм аз гына баллы тамырларын көз көне казып алып чи килеш ашыйлар яки табада кыздыралар. Әрекмән белән туклану гына түгел, аның күп кенә дәвалау үзлекләреннән дә файдаланырга була. Аның яфракларында аскорбин кислотасы (С витамины, температураны төшерү өчен) белән беррәттән эфир мае бар. Әрекмән яфракларыннан алынган эфир маен җәрәхәткә сөртү өчен, экзема, чуан чыкканда файдаланыла. Яфракларыннан тәнәтмә ясап, чәчне юалар. Ул чәч үсүне яхшырта, кавыкны бетерә. Бигрәк тә әрекмәннең тамыры файдалы. Беренче елында чәчәк атканчы, тамырны казып алып юалар, озынча көйгә тишкәләп киптерәләр. Бер елдан артык сакларга кинәш ителми: ул дәвалау үзлекләрен югалта.

Әзәрбайҗаннар әрекмәнне – пытрач, әрмәннәр – кратук, грузиннар орованди дип атыйлар. Көз житеп, әрекмәннең җимешләре өлгергәч, шул тигәнәк урманы аша узарга туры килсә, шаккатасың, бөтен киемдә тигәнәкнең йомры җимешләре. Аның ябышу сәләтен генә карагыз, һәр бөртекнең өске өлеше кармак кебек аска бөгелгән. Әләктереп алдымы, ычкыну юк. Ә син ачу белән аларны берәмтекләп йолкып атасың. Аңа шул гына кирәк тә: киләсе елга син ташлаган урында һичшиксез иртә язда ул әрекмән тишелеп чыгачак.

Гомәр ШАКИРОВ.
Әтнә районы,
Иске Җөгып авылы

Заманга ярашып

БУАЛАР САГЫНДА

Татарстан бөтен Россиядә мелиорация системасы сакланып калган аз-маз төбәкләрнең берсе.

Авыл хуҗалыгыннан тыш, экология өчен дә гаять мөһим роль уйнаучы бу тармакның таркалмый калуы, беренче чиратта, "Татмелиорация" генераль директоры Әнвәр Залаков исеменә бәйле. Тик бер кризис икенчесе белән тоташкан безнең заманда аның бу эшне гөрләтеп торуы үзенең оештыру сәләтенә генә бәйле түгел. Урыннарда генераль директорның һәр идеясен җиренә җиткерерлек алтын баганалары бар. Балык Бистәсендә андый терәк – районның сугару-киптерү системаларын файдалану идарәсе башлыгы Рәис Кыям улы Җамалиев. Гәрчә идарә үзе "Татмелиорация"нең филиалы булып торса да, Мәскәү тарафларыннан уздырылучы "вертикаль төзү" сәясәте биредә дә үзен сиздерә: бер гектарлы биләмәләрдәге житештерү базасы һәм корпусы, административ бина һәм складлар федераль милек булып санала икән. Төп вазифалары – райондагы сугару системаларын төзекләндерү һәм аларны эшләрлек хәлдә тоту. Райондагы егерме буа 2006 елдан муниципаль берәмлек карамагына бирелгән булса да, идарә белгечләре аларны ярдәменнән ташламый. Чөнки буаларны төзек тотардай белгечләр һәм тиешле техника фәкать аларда гына. Аеруча язгы ташу вакытында мәшәкатьләре арта. Быел, мәсәлән, ике күчмә бригада оештырганнар. Былтыр иң күп эш Олы Елга буасында башкарылган. Аңа күптәннән ремонт кирәк булганга, авыл җирлеге житәкчесе белән бергәләп, проект-смета документлары эшләтү өчен Казаннан белгечләр чакырганнар. Ишелү куркынычы янаган гидротехник корылманы төзекләндерү 600 мең сумга төшкән. Ә яңа буа кору өчен кимендә 4-5 млн сум кирәк булыр иде.

Бүген бу районда авария хәлендәге берничә буа бар. Инде шуларның икесенә ремонт ясау өчен проект әзерләнә. Казаклар авылындагысын төзекләндерүгә быел ук акча бүләргә ышандырганнар. Солтан, Бәтке, Казак Чаллысы авыллары буалары да, мелиораторлар ярдәмгә килмәсә, озак торырлык түгел. Мондый эшләрне идарә уңганнары бернинди кыенлык күрмичә, үз көчләре белән башкарып чыга ала. Әгәр инде яңа буалар төзү яисә масштаблырак ремонт эшләре башкару кирәк булса, 7нче механикалаштырылган күчмә колонна базасындагы "Строймонтаж" белән килешү нигезендә эшләү мөмкинлеге бар. Шулай ук Мамадыштагы ПМК "Мелиорация" ААҖ директоры Ренат Мостафин куәтле техника белән ярдәмгә килергә һәрчак әзер.

Сугару буенча төп эш чәнлек Олы Елга авылында җәелдерелгән. Анда "Фрегат" маркалы биш сугару җайланмасы күптәннән файдаланыла. "Кама" агрофирмасы биләмәләрендә барлыгы 472 гектар сугару җирләре бар. Шуның 50 гектары – мәктәп карамагында. Быел агрофирма соравы буенча яңа сугару системасы көйлиләр. Анда магистраль торбалар сузу чыгымнарын федераль бюджет хисабына алып барылса, Чехиядә ясалган ике "Одра" су сиптерү җайланмасын республика сатып алган. Үзләре ремонтлаган буадан су алу өчен куелган насос станциясе дә төзек хәлдә.

Замана үзгәрүен мелиораторлар һәрдаим тоеп тора. Кайчандыр "Волжанка"лар белән су сиптергән булсалар, инде – "Фрегат"лар һәм тагы да камилләшә төшкән "Одра"лар кулланылышта.

– Яңа технологияләр кертү җәһәтеннән аерата инженер Хәниф Төхвәтуллинның өлеше бәһаләп бетергесез, – дип таный Рәис Җамалиев. Техниканы биш бармагы сыман белүче Рамил Хәмидуллин да коллектив горурлыгы.

Эшсезлек янаган бу заманда кулың белгән эшкә ябышып ятарга, хезмәтнең кадерен белергә кирәклеген биредә һәркем – бухгалтерлар Нурзидә Әлмөхәммәтова, Лилия Газина, экскаваторчы Альберт Сафин, эретеп ябыштыручы Олег Попов та бик яхшы аңлый.

Рәис ЗАРИПОВ

Казансуга ярдәм килә

Дмитрий БУНТУКОВ

ЕЛГАЛАРНЫ КОТКАРЫЙК!

Арча районы үзәгендә Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы составындагы Төньяк территориаль идарә эшләгәнен күптәннән белсәм дә, аның карамагында нинди киң мәйдан булганын күз алдына да китерә алмый идем.

Күптән түгел, форсат чыгып, идарә башлыгы **Фаил әфәнде Мөхәммәтшин** белән очраштык. Идарә вазыйфаларына Арча, Балтач, Кукмара һәм Әтнә районнарында тирә-як мохитне тикшереп, табигать сагында тору керә икән. Балтач һәм Әтнә районнарындагы "Ашыт", "Балтач" тыюлыкларын да, һәр район чигендәге аерым саклану мәйданнарын да, Арча районындагы соры челән төркемен идарә хезмәткәрләренең һәрдаим күз уңында тотуы зарур.

– Фаил Камалович, мохит дигәнең – шактый күләмле төшенчә, ул җир, су, һава һәм табигый энергияне үз эченә ала. Сез җитәкләгән идарә аларның кайсысына игътибарны күбрәк юнәлтә?

– Эльвира Гаязова житәкчелегендәге аналитик контроль лаборатория 2004 елдан бирле эшли. Биредә белгечләребез туфракның һәм сулыклардагы суның сыйфатын даими күзәтәләр, заманча әйткәндә, мониторинг ясыйлар. Һава чисталыгын да, кирәк булса, газ анализаторы ярдәмендә тикшерәбез. Хәер, безнең төбәктә һаваны пычратучы предприятиеләр юк диярлек, сизелерлек дәрәҗәдә зыянлысы биредәге иске асфальт заводы иде. Хәзер ул эшеннән туктатылды. "Татавтодор"-Германиядән яңа корылма кайтартты. Анысы алман технологиясе нигезендә һава сафлыгына зыянсыз эшләячәк. Шуңа күрә көндәлек эшебездә күбрәген авыл хуҗалыгына кагылышлы тикшеренүләргә өстенлек бирәбез.

– Хәзер элекке колхоз-совхозлар урынында инвесторлар карамагындагы хуҗалыклар пәйда булды. Инвесторлар экология проблемаларына нинди рәвешле карашта? Калада яшәгән хуҗалар, сала халкының саф мохиттә яшәү теләгән исәпкә алмыйча, "аз чыгым – зур табыш" шигаре астында Экология кодексына каршы гамәлләр кылмыймы?

– Андый омтылышлар булгалый. Әмма бу очракта штрафларның юридик затлар өчен бик зур булуын алар яхшы белә бит. Хәзер физик затлар өчен дә штрафлар артып, 1000 нән 2000 сумга кадәр күтәрелде. Закон бозуның кыйммәткә төшәчәген эшмәкәрләрнең күпчелегә хәзер яхшы аңлый…

– Әмма штраф белән янап кына мохитне сафландыра алырбыз микән?

– Кеше дигәнең ифрат сәер җан иясе бит ул. Үз ишегалдында оҗмах ясаган адәм баласы шакшы сыекча белән "сугарылган" чүп-чарын чиләге белән урам уртасына чыгарып аудара, иске-москыларын, мәсәлән, иске юрганнарын һәм матрасларын ахшам вакытында (!) юл буендагы каенлыкка яисә иней ярындагы куаклыкка илтеп ташлый. Хәтта яшереп тә маташмый. Бәйрәм яисә якшәмбе кичендә район үзәкләренең автобус тукталышларын күрегез, шаккатарсыз. Анда, бишалты урна тезеп куйсаң да, чүп-чар барыбер җиргә ыргытылачак. Һәр каен яисә автобус тукталышы янына инспектор бастыра алмыйсың бит инде. Шакшы суларын урамга чыгарып түгүче "гүзәл" затлар да аңласын иде: берничек тә үз утарыңда герметик ябылган оҗмах булдыру мөмкин түгел. Шул шакшыны татыган чебен, өйдәге ипи киштәсенә барып житә алмас, яисә бакчадагы җиләк-җимештән авыз итми калмас, дип уйламагыз. Ул җимешнең балаларыгыз яисә оныкларыгызның авызына юылмаган килеш эләгүе дә ихтимал.

– Кыскасы, көнкүреш калдыкларының теләсә кая түгелүе хәзер саланы да бик хәтәр хәлгә житкергән икән.

– Иң кыен проблемаларның берсе шул дисәм, шәт, ялгышмамдыр. Аны хәл итү өчен һәр шәхеснең үз-үзен тәртәдә тотуы, гаиләнең балаларын тәрбияләве, мәктәпнең тырышлыгы, җирле үзидарәнең активлыгы зарур. Әмма бу гына аз. Иң мөһиме – адәм баласының мохиткә үз анасына караган шикелле ихтирамлы, әдәпле мөнәсәбәте кирәк. Кыскасы, безгә менталитет дигән нәрсәне нигездән үзгәртергә вакыт. Читтән килеп беркем дә үзебез туплаган чүпне жыеп йөрмәс. Кем әйтмешли, "чисталык дип көрәшү кирәкми, себерү зарур".

– Чүпнең бер төре бар. Аның туплануында бернинди эшмәкәрнең дә, җирле халыкның да, төрле дәрәҗәдәге хакимият вәкилләренең дә гаебе юк.

– Соравыгызны шәйлим. Тимер юл буенда жыелып, күбрәге пластик савыт-сабалардан торган чүплекләрне күзаллыйсыз. Бу проблема министрлыкның коллегия утырышларында берничә тапкыр күтәрелде инде. Тимер юл узган төбәкләрне ул мәсьәлә бик борчый. Тик аны бер республикада гына хәл итү мөмкин түгел. Мәсьәлә ил күләмендә күтәрелергә тиеш. Әмма шулай да бу проблеманың "югарыдан" төшкән чишелешен көтеп кул кушырып утыру дөрес булмас. "Астан" активлык күрсәтеп, тимер юл бүлекчәләрен прокуратура аша җавапларлыкка тарта башласак, "өстәгеләргә" проблеманы гомуми хәл итү өчен көчле этәргеч булыр иде. Андый эш башланды дияргә ярый.

– Чүп бердәнбер читен проблема түгелдер, мөгаен.

– Икенчесе – тирес таулары. Мал асраучы хуҗалыкларда тирем өемнәре бик тиз калкып чыга. Андый калдыклар туфрак белән сулыкларны пычратып кына калмый, без сулый торган һавага да сәламәтлек өчен зыянлы матдәләр өсти.

– Органик калдыкларны файдалану технологияләре билгеле бит югыйсә…

– Шулаен шулай да соң, аларны гамәлгә кертү өчен шактый зур чыгымнар кирәк бит. Соңгы вакытларда шул органик калдык запасларын биогаз житештерүдә файдалану турында сүз бара. Тик эшмәкәрләр яңа эшкә алынабыз дип атлыгып тормый. Әмма килер бер көн, бу юнәлештә практик гамәлләргә дә чират житәр…

– Читтән килгән кунаклар Арчаның елдан-ел төзекләнә һәм матурлана баруына исләре китә. 2008 елның җәендә Казансу яры буенда башланып киткән ифрат зур төзелеш мәйданы әзерләнә башлады. Күңелдә тагын бер сорау тудыра: монысы нәрсә булыр икән инде? Заманча техника ярдәмендә җәяүле һәм транспорт күперләре арасындагы, елга буенда агачларны күпләп аудару күңелгә ниндидер шом сала хәтта.

– Сез "мәйдан әзерләү" дигән күренеш – зур эшнең башы гына ул. Моннан утыз еллап элек табигый һәйкәл дип игълан ителгән Казансу саега, төбенә ләм утыра, яр буендагы агачлардан сынып төшкән ботаклардан чытырманлык хасил була. Шуңа күрә елганы элекке кебек саф, чиста итеп саклап калу чаралары күрергә кирәк иде. Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы моның проектын әзерләтте. Аның буенча Казансу ярларының Арча тирәсендәге өлешен ныгыту карала. Котырып үскән агачлар урынына эре булмаган куаклар утыртып, үлән чәчү күздә тотыла. Күрәм, табигатькә шундый "тыкшыну" урынлы микән, дип шикләнәсез. Бәхәсләшмим, галим Коммонер ачыклаган законнарның берсе болай: "Табигать үзе яхшырак белә". Казансу үзенең ниндидер юнәлештә, ниндидер үзән буйлап агарга тиешлеген, чынлап та, кешегә караганда яхшырак "белә". Әмма аның үз яшәешенә без шулкадәр зыян салып өлгердек, хәзер аңа чистарныргa ярдәм итәргә туры килә. Бу сүз башындагы мәсьәлә – халыкның табигатьне рәнҗетүенә бәйле. Әгәр елга ярларын чүп-чар базына әйләндереп бетермәсәк, тирес сулары һәм башка төр сыеклыклар агызып бозмасак, ул үзен-үзе чистартып өлгерер иде. Тик бүген сулыкларга басым шулкадәр көчле, алар ярдәм сорап илерәләр.

– Соңгы соравым: бу мәсьәләдә сезгә кем ярдәмгә килә?

– Заказчы – Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, финанслау – федераль бюджет хисабыннан, ә подрядчысы – уналтынчы механикалаштырылган күчмә колонна.

Әңгәмәдәш – Ким ШАКИРОВ

Медицина калдыклары тудырган афәт

Бер авыруның урыны (койка) елына 416 кг медицина калдыгы "бирә"

БОРЧЫГАН МӘСЬӘЛӘ

Соңгы елларда чүп-чарга карата төрле өлкә белгечләренең игътибары нык артып китте. Хәзер аның сәнәгать, төзелеш, транспорт, медицина, биология (хайваннар, кош-кортлар), экология, авыл хуҗалыгы калдыклары кебек бик күп кенә төрләрен аерып чыгардылар. Чөнки бүген әлеге чүпләрне җыю, саклау, юк итү, алардан икенчел чимал барлыкка китерү кебек проблемалар тыгыз рәвештә санитария-эпидемиология, экология, техника һәм социаль мәсьәләләргә килеп бәйләнә.

Белеп кенә бетермибез

БМО мәгълүматлары буенча, илдә барлыкка килә торган авыруларның 25тән алып 33 процентка кадәресе турыдан-туры кешене чолгап алган тирә-як мохиткә, аның начар хәлдә булуына бәйле икән. Кешенең вакытыннан алда үлү очракларының 18 процентына шулай ук табигый һаваның чиста булмавы сәбәпче. Шуның бер проценты сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларының тискәре йогынтысына туры килә.

Закон телендә үлем очраклары күбәюгә яисә катлаулы чир белән зарарлану очракларына, гариплеккә китерүче авыруларга сәбәпче булган, шулай ук эшкәртү, саклау, ташу, юк итү процесслары дөрес башкарылмаган очракта хәзер һәм киләчәктә кеше сәламәтлегенә һәм тирә-як мохиткә зарар белән янаучы калдыклар "куркыныч" дип билгеләнә. Базель Конвенциясе 1992 елда иң куркыныч дип табылган калдыкларның 45 төрен билгели. Әлеге исемлек медицина калдыклары белән башланып китә.

Дәвалау учрежденияләрендә барлыкка килә торган чүп-чар табигате белән үк зарарлы. Моны белгечләр дә раслады, медицина учрежденияләре дә таныды. Ләкин шуңа да карамастан, составында төрле химик матдәләр, радиацион һәм йогышлы

факторлары булган әлеге калдыклар белән эш итү алымнары безнең илдә әле һаман да тулаем билгеләнеп бетмәгән. Дөрес, проектлар юк түгел үзе. Әмма алар әле һаман да "каралу"дан узмаган. Татарстан сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Гадел Вафин сүзләренә караганда, мондый калдыкларны жыю һәм юк итү исуллары соңгы ун елда бернинди дә үзгәреш кичермәгән. Ә дару составлары исә, киресенчә, сизелерлек дәрәҗәдә катлаулана бара.

Узган 2008 елда республикабыз территориясендә генә дә 24 мең тоннадан артык медицина калдыгы барлыкка килгән. Россия буенча әлеге күрсәткеч 3,5 миллион тоннадан (!) да артып китә. Сәламәтлек саклау учрежденияләре һәм оешмаларында калдыкларга дип планлаштырылган заманча җайланмаларның житмәве бүген көн кадагындагы мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Хәтта 2006 ел белән чагыштырганда, андый калдыкларны юк итү җайланмаларының саны Россия буенча алганда ун процент чамасы кимегән дә әле. Ә бит прививка ясау, ВИЧ кебек йогышлы авыруларны дәвалаудан жыелган калдыклар мәсьәләсен исәпкә алсаң, хәлнең мөшкел булуын аңлавы кыен түгел. Статистика буенча, вакцина ясаганнан соң барлыкка килгән калдыкларның 80 проценты йогышлы чир тарату үзлегенә ия.

Бер үк шприц кулланып эш итү нәтиҗәсендә бер авыруның чирен икенче кешегә йоктыру куркынычы зур булганлыктан, инде күптәннән бер генә тапкыр кулланыла торган медицина җиһазлары әйләнешкә кертелде. Бу күренеш, бер яктан, чиргә сак карауны арттырса, икенче яктан, калдыклар саны артуга да сәбәпче булды. Шул сәбәпле белгечләр алдында әлеге үзгәрешләрне сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да чагыштырып карау зарурлыгы килеп туды. Мисал өчен, РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының "ДЕЗИРС" дәүләт унитар предприятиесе белгечләре 1999-2001 елларда нәкъ менә шундый тикшеренүләр өстендә эшләделәр.

Тикшерү барышында дәвалау учрежденисендә кулланылышта булган бер авыру койкасына елына 416 килограмм калдык туры килүе ачыкланган. Бу күрсәткеч министрлык тарафыннан куелган нормадан ике тапкыр диярлек артып китә. Микроорганизмнар тарату иялеге буенча да күпсанлы гына тикшеренүләр уздырылган. Белгечләр калдыкларның гына түгел, ә аларның тирә-ягындагы җайланмаларның да (савыт-саба, мебель һ.б.) стафилококк, эчәк таякчыгы кебек микроорганизмнар белән "зарарланган" булуын ачыклаган. Шәһәр чүплекләренә чыгарып ташлана торган калдыкларның 30 проценты кешелек өчен эпидемия куркынычы белән яный икән. Әлеге микроорганизмнар озак яши алу белән бергә бик тиз үрчү үзенчәлегенә ия. Аннан соң медицина калдыкларындагы микроорганизмнарның төрле эшкәртүләргә карата да чыдам булуы билгеле. Хәтта шәһәр чүплекләрендә көн күрүчеләрнең чүп аралау нәтиҗәсендә В гепатиты һәм ВИЧ инфекциясе белән зарарлану очраклары да ачыкланган.

Чишелеш булырга тиеш

Медицина калдыклары белән эш иткәндә куркынычсыз шартлар тудыру өчен закон һәм техника житәрлек дәрәҗәдә түгел. Мисал өчен кулланылыш вакыты узган, таможня хезмәткәрләре тарафыннан конфискацияләнгән, ялган дип табылган даруларны кая кую, ни рәвешле юк итү мәсьәләсен генә алсак та, монда бернинди ачыклык юк.

Шуңа күрә әлеге өлкәдә күзәтчелек белән шөгыльләнүче идарә органнары, сәламәтлек саклау учрежденияләре өчен медицина калдыклары белән эш итүнең яңа алымнары, яңа таләпләре зур кысыксыну тудыра. Әлбәттә инде, республиканың Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы да әлеге мәсьәләләрне чишүдән читтә кала алмый. Шул уңайдан министрлык Халыкара конференция үткәрү башлангычы белән чыкты. Күптән түгел Казан сәнәгать үсеше буенча БМО (ЮНИДО) вәкилләрен кабул итте. Биредә Венгрия, Румыния, Канада һәм Франция кебек төрле илләрдән килгән йөздән артык белгеч катнашты.

Әлеге Халыкара конференция нәтиҗәләренә министр Әгъләм Садретдинов бик зур өметләр баглый.

– Бу конференция медицина калдыклары белән эш итү өчен кирәк булган стратегияне формалаштыруга зур өлеш кертәчәк, – диде ул чараны ачу вакытында. Министр фикеренчә, ЮНИДОның эш тәжрибәсе, Глобаль экология фонды тарафыннан тәкъдим ителә торган уртак финанслау механизмнары, Стокгольм Конвенциясе тарафыннан тәкъдим ителә торган яңа технологияләр аеруча игътибар үзәгендә булырга тиеш. Чөнки конференциянең төп максаты – халыкара тәжрибәләр белән уртаклашу. Шулай булгач, бер илдә нәтиҗәле механизм уйлап табылган икән, ни өчен әле аны башка илдә уйлап азапланырга? Фәкать кулланырга гына кирәк.

ЮНИДОның тирә-як мохиттә таркалмый торган химик матдәләр (СОЗ) буенча проектлар житәкчесе Валентин Ищенко (Австрия) әйтүенчә, медицина калдыкларын юк итү проблемалары күпчелек илләргә хас. Шуңа бәйле рәвештә бу өлкәдәге киртәләр дә бертөсле диярлек. Әйтик, шул ук закон проектларын камилләштереп бетерү, халыкның әлеге өлкәгә карата мәгълүматлылыгын арттыру, таркалмый торган химик матдәләр эшләп чыгаруны киметү, моңа белгечләрнең игътибарын арттыру кебек эшләрнең әлегә иге-чиге күренми.

Россия өчен бу өлкәдәге төп каршылык – медицина калдыклары өчен жавап бирерлек бердәм дәүләт органының булмавы. ЮНИДОның әлеге мәсьәләгә карата үз фикере һәм планнары бар. Халыкара сәнәгать хезмәттәшлеге үзәге белгечләре Татарстанның ике министрлыгы (Экология һәм табигый байлыклар, Сәламәтлек саклау) белән берлектә республикада барлыкка килгән медицина калдыкларын юк итү буенча пилот проектын тормышка ашырмакчы булалар.

Әлегә ЮНИДОның Россиягә бер тиен дә акча биргәне юк. Ул Глобаль экология фонды таләпләренә туры килә торган план проектлары төзесә генә, аларны тормышка ашырырлык матди ярдәмгә өмет итә ала. Шуңа күрә, руслар әйтмешли, "дело остается за малым". Чөнки ЮНИДО бертавыштан, без ярдәм итәргә әзер, дип белдерә. Татарстан экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары Владимир Марьев әйтүенчә, Татарстан әлеге пилот проекты өчен әзер. Һәрхәлдә, министрлык моның өчен барысын да эшләячәк, дип ассызыклады ул.

Чулпан ХӘЙРУЛЛИНА
Гөлназ САТИЕВА фотолары

Кушымтаның мөхәррире – Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА, биткә салучы һәм бизәүче – Зөлфия МАДЬЯРОВА